

Олылар айлыгы кысаларында Зубово-Поляна районы Горенка мәктәбе укучылары олыларны зур ихтирам белән котлап чәчәкләр бәйләмнәре тапшырганнар. Без бу мәкаләдә Горенка, Татар Лунданы, Кочетовка татар авыллары зирәк һәм соекле апа-абыйлары, әби-бабайларына тукталырбыз. Айлык тәмамланды, әмма хормәтләv дәвам итә.       Беренче октябрьдә Россиядә олы яшьтәге кеше коне билгеләп vтелә. Бу игелекле һәм якты бәйрәм, анда әти-әниләребез, әби-бабаларыбызнын аерым игътибарын жәлеп итәләр. Бу - гомер буе туган илебез файдасына хезмәт итvгә, балаларны тәрбияләvгә багышлаган зирәк һәм соекле кешеләр бәйрәме. Бәйрәм жәмгыятьнен россиялеләрнен ол-кән буыннарына карата хормәте, рәхмәте һәм яратуы; аларнын жилкәләренә шулкадәр кvп мохтажлык, кайгы, газаплар һәм фидакарь хезмәт тошкән.



Тирә-юньдәге кешеләргә шатлык бирvдән һәм жавап итеп эчкерсез һәм якты хисләр алудан да рәхәтрәк нәрсә юк. Бу эшне балалардан да яхшырак беркем дә башкара алмый. Чонки нәкъ аларны игелекле, якты һәм эчкерсезнен чын хәзинәсе дип атарга момкин. Горенка мәктәбендә укучыларга патриотик тәрбия бирvгә зур игътибар ителә. Билгеле булганча, патриотизм туган якны яратудан, олкәннәрне хормәт



итvдән башлана. Бу мәктәп укучылары, традиция буенча, олы яшьтәге кешеләрнен йортларына котлаулар белән киләләр.

Укучылар Махинур Хосәен кызы белән Кадрия Хосәен кызы Маминаларны, Махира Сабиржан кызы Немишева янына килеп, аларны олы яшьтәге кеше коне белән котлаганнар. Хезмәт ветераннары игътибарлары очен укучыларга чын кvнелдән рәхмәт белдерделәр. “Кадерле укучылар! Олкән буынга карата шундый ихтирамлы монәсәбәтегез безгә бик ошый. Бу – халкыбызнын коче”, – дип кинәш бирде балаларга хезмәт ветераны Махира Сабиржан кызы Немишева.

*Фотолар Горенка мэктэбе, Кочетовка авылы ВКонтакте социаль челтэрлэреннэн алынды*